


Боек Ватан сугышында катнашучынын һәр исеме артында кеше язмышы, тормыш. Бу - торле буын, милләт, һонәр, сәләт кешеләре, әмма аларнын барысын да туган жиргә, vз Ватанына карата кайнар мәхәббәт хисләре берләштерде.

Бу элемтә озелмәсен, чонки һәр гаиләнен Жинvдә vз олеше бар. Сугыш безнен тормышыбызда бик зур эз калдырды, кvп кешеләрнен язмышларын vзгәртте. Хә- зерге буынга да тыныч тормыш тәэмин итvчеләрне истә тоту моһим.
Мин бабаем, гаиләм герое - Исмаил Хәмзә улы Капкаев, игелекле кеше турында сойләргә телим. Балалары, оныклары очен ул хезмәт соючәнлелек, кешеләргә һәм әйләнә-тирә табигатькә мәхәббәт vрнәге булды. Әбием Наилә Исмаил кызы Янбулатова сvзләренә караганда, мина билгеле булганча, Капкаевлар гаиләсеннән биш ир-егет фронтка киткән. Очесенә әниләре похоронка алган. Тик ике улынын исән – сау булып кайтуларын Ходайдан сорап алган; алар туган якларына жинvчеләр булып кайтканнар. Исмаил Хәмзә улын Большие Поляны авылында элемтәче белгеч, әзер ләv конторасы хезмәткәре буларак хәтерлиләр. Ул, ашыгыч хезмәттә булганда, элемтәчеләр курсын тәмамлый. Тыныч вакытта да, сугыш вакытында да ана бу һонәр бик тә кирәк була. Сугышка кадәр элемтә бvлеге начальнигы булып эшләргә дә олгергән ул. Связист буларак сугышта да корәшкән - Мозырьский дивизиянен 6-нчы артиллерия Идарәсенен. батарея бvлеге командиры. Бабаем vзенен сугышын Белоруссиянен  Оршасында каршы ала. Каты контузияләнә. Янадан сафка баса.  Алда 1418 кон һәм тон озынлыгында сугыш - Боек Жинvгә юл.
«Халык хәтере» сайтынын архив чыганакларыннан һәм электрон ресурслардан файдаланып, мин Польшада Висла елгасын форсировать иткәндә, бабамнын алдынгы линия буенча элемтә тотуын белдем. 1944 елнын 23 октябрендә, операция башланыр алдыннан, Згеже районында артиллерия уты белән 118 бригадага элемтә vтә торган чикне дошман бертуктаусыз ата. Ут эчендә дә кызылармеец Капкаев линиядә була һәм шунда ук снарядлар шартлавыннан озелгән элемтәне тоташтыра. Шулай итеп, ул кыска вакыт эчендә 13 элемтә озеген тоташтыра; бу дивизия командиры ягыннан ботен бер бригада ут белән житәкчелек итvне тәэмин итә. Хокvмәт бvләге – «Батырлык очен»

медале белән бvләкләнә (Приказ №48/н от 13.11.1944 года издан 4 акп РГК 1-го Белорусского фронта). Берлинны алганда да сугышчы И.Х.Капкаев батырлыгы белән аерылып тора. 1945 елнын апрелендә батырлыгы очен Кызыл Йолдыз Ордены (Приказ №11/н от 01.06.1945 года издан 6 гвард.артд РГК) белән бvләкләнә».
Олкән сержант булган Исмаил Хәмзә улы Капкаев Одер елгасынын конбатыш ярында плацдармны кинәйткәндә дә кыюлык һәм батырлык кvрсәтә. Бvлекчә сугышчылары плотик һәм су киртәсе корганнар, анын аша элемтә дә салганнар. Ә бу 800 метрга якын! 20 минут эчендә! Аннан сон бvлекчә, кискен ату астында, кvзәтv пунктлары арасында озлексез элемтә булдырды. Бvлек командиры vзе 10 минут эчендә сигез прорывов тозәтеп, девизиянен кvзәтv пункты белән бригада пунктынын эшен тәэмин иткән. Бу бабаем батырлыгынын бер эпизоды гына. Сугыш еллары вакытында шундый кvп переправалары - Западная Двина, Днепр, Висла елгаларын кичкән булган. Һәм бу бер генә вакыйга турында сойләдем, шундыйларнын кvбесен белмибез дә. Сугыш елларында Конбатыш Двина, Днепр, Висла артында мондый кичvләр кvп була. Герой бабаем, Исмаил Хәмзә улы Капкаев, 1985 елда Жинvнен 40 еллыгы унаеннан II дәрәжә Боек Ватан сугышы Ордены белән бvләкләнә.
Быел илебез фашист Германиясен Жинvгә 75 ел тулуны бәйрәм иттек һәм ел буе итәчәкбез. Минем уйлавымча, бабам минем унышларым белән горурлана алыр иде. Мин - Беренче Мәскәv кадетлар корпусы кадеты. Кызыл мәйданда Жинv Коненә багышланган парадта да катнашачакмын. Яшь армиячеләр сафында vтәрмен. Бу минем очен зур дәрәжә. Боек Ватан сугышы вакыйгаларынын фактларын һәм таныклыкларын кулланып, мин бабам Исмаил Хәмзә улы Капкаевнын нинди Герой булуын белдем. Мин анын белән горурланам!

**Роман МИХАЛЕВСКИЙ,**
*И.Х. Капкаевнын правнугы*